ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2021 ел №353

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарларны үз көчен югалткан дип таныргa:

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 15 маендагы 188нче номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган җимерү һәм капиталь төзелеш объектын җимерүне төгәлләү турында хәбәр итү юнәлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 июлендәге 256 номерлы карары;

«Муниципаль милектәге яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 15 мартындагы 65 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 25 мартындагы 106 номерлы карарының 1.2, 1.5, 1.15 п.;

«Муниципаль милектәге яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның

11 мартындагы 64 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен үткәрү турында» административ регламентны раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 07 маендагы 173 номерлы карары.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**